**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 гыйнвар № 34

г. Казань

«Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең исемен «Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр хуҗалыгы көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе дип үзгәртү турында

Квалификацияле кадрларны өзлексез һөнәри әзерләүне оештыру, төрле профильдәге программаларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, «Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе педагогик коллективының көллиятнең исемен «Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр хуҗалыгы көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр хуҗалыгы көллияте) дип үзгәртү турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр хуҗалыгы көллиятендә укучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

60 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләр кертергә:

«Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе уставына;

«Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсенә.

3. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә,

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, «Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 9 ноябрь, 830 нче карарына аны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\34.docx